Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№4 (134)

12 март 2015 ел



Фотода БДПУның Татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире И. Нәсипов һәм Э.Нәҗипова. Алия Уразбахтина фотосы

# Хөрмәтнең башы - хезмәт

**«Дөньяда гакылдан шәриф нәрсә юк вә рух байлыгыннан артык байлык юк. Берәү чит телне өйрәнәсе булса, башта үз телен яхшы белсен...** » – дигән бөек мәгърифәтче-галим, педагог Каюм Насыйри.

Укытучы булу өчен теләк кенә аз. Сиңа заман белән бергә атларга, күпмедер күләмдә психолог булырга, үз сәләтеңне үстерү максатыннан тәҗрибә тупларга омтылу кирәк. Университетыбызда белем алучы һәм укытучы булырга хыялланучы студентларыбыз Башкортстан Республикасының башкаласы – Уфа шәһәрендә узган «Ана теле – 2015» педагогик осталыкны үстерү буенча VII Бөтенрәсәй студентлар бәйгесендә үзләрен сынап карый алды. Бу чара бөек мәгърифәтче-галим, педагог Каюм Насыйриның тууына 190 ел тулуга багышланган иде.

## • Вакыйгалар эзеннән

Президент **РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ** җитәкчелеге астында КФУ ректоры **ИЛШАТ ГАФУРОВ**, Татарстанның әйдәп баручы сәнәгать оешмалары һәм министрлыклар җитәкчеләре Ислам Республикасы – Иранга өч көнлек эшлекле сәяхәт кылды.

Р.Миңнеханов һәм И.Гафуровның Шахид Бехешти исемендәге Тегеран университетына барулары һәм аларның уку программалары белән танышулары КФУ өчен мөһим гамәлләрнең берсе булды. Искәртеп үтик: 2014нче елның сентябрендә КФУ белән Шахид Бахешти ис. Тегеран университеты арасында аспирантларның алмашып укуы турында килешү төзелгән иде. Килешү нигезендә, елга 10 аспирант Иранда белем ала, фәнни чараларда, эксперименталь физика буенча җәйге курсларда катнаша ала. Сөйләшү барышында Иран студентлары өчен грантлар санын арттыру тәкъдиме дә яңгырады.

• • • •

Ел дәвамында Казан федераль университеты 15 фәннән **РЕГИОНАРА ОЛИМПИАДА** уздыра. Мондый зур чаралар илнең төрле регионнарыннан КФУга сәләтле балаларны җыю өчен эшләнә. 2014-2015нче уку елында гына да ике мең ярымга якын 9-11нче сыйныф укучылары математика, информатика, физика, химия, биология, география, геология, җәмгыять белеме, тарих, татар, рус, инглиз, француз, алман телләреннән һәм әдәбиятыннан үз белемнәрен сынап карадылар.

Үзенчәлекле биремнәр төзү белән КФУның алдынгы укытучылары шөгыльләнә. Олимпиаданы уздыру өстендә, Югары уку йортына кадәр, гомуми һәм педагогик белем бирү департаменты эшли.

Фәнни олимпиадалар мәктәп укучыларының фәнни потенциалларын ачса, университет өчен профориентация эшчәнлеген алып бару, сәләтле абитуриентлар җыю өчен дә мәйдан булып тора.

Шунысы мөһим: 2015-2016нчы елгы кабул итү кампаниясендә олимпиада җиңүчеләренә, БДИ нәтиҗәләренә өстәп, 2, призерларга 1 балл куелачак.

• • • •

8нче март уңаеннан КФУда Университет хатын-кызлары лигасы тарафыннан уздырыла торган **«ЕЛ ХАТЫН-КЫЗЫ. ХАТЫН-КЫЗ КҮЗЛЕГЕННӘН ЧЫГЫП, ЕЛ ИР-АТЫ»** бәйгесенә йомгак ясалды.

Сәламләү сүзе белән Университет хатын-кызлары лигасы җитәкчесе, КФУның туктаусыз белем бирү институты директоры урынбасары **ИРИНА ТЕРЕНТЬЕВА** чыгыш ясады. Ул әлеге бәйгенең 1993нче елдан бирле оештырылып килүен һәм университетның гүзәл затларын олылавы белән үзенчәлекле булуын ассызыклады.

«Җитәкче хатын-кыз» номинациясендә финанслар буенча проректор **РӘИСӘ МУЛЛАКАЕВА** җиңүче дип табылды. «Галим – хатын-кыз» номинациясендә **СТЕЛЛА КОРАБЛЕВА** билгеләп үтелде.

«Ел хатын-кызы. Хатын-кыз күзлегеннән чыгып, ел ир-аты» бәйгесендә, «Үрнәк хатын-кыз», «Университет гореф-гадәтләрен саклаучы хатын-кыз», «21нче гасыр укытучысы – хатын-кыз» кебек өлкәләрдә җиңүчеләр билгеләнде. «Ир-ат – ел җитәкчесе» номинациясендә җиңүче дип Юридик факультет деканы **ИЛДАР ТАРХАНОВ** танылды.

Әлеге бәйге КФУда иң лаеклы укытучылар, белгечләр эшләвенә тагын бер дәлил булып тора.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды.*

## • Мөнбәр

# Хөрмәтнең башы - хезмәт

**Айгөл АБДРАХМАНОВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

5-6нчы март көннәрендә М.Акмулла исемендәге Башкорт Дәүләт педагогия университеты көрәш мәйданына әверелде. Монда студентларның VII Россия күләмендәге «Ана теле-2015» педагогик осталык бәйгесе уздырылды. Быелгы ярыш татар галим-этнографы, педагогы, мәгърифәтчесе, язучы Каюм Насыйриның 190 еллыгына багышланган иде.

Бәйгенең төп максаты – татар теле һәм әдәбияты укытучысы булырга теләүче студентларны барлау, араларыннан иң-иңнәрен сайлап алу һәм киләчәккә юл ачу. Бәйге берничә өлештән тора. Беренче баскычта студентлар бәйгедә катнашырга лаек булуларын дәлиллиләр, икенче баскыч – читтән торып сайлап алу туры. «Ана теле - 2015» бәйгесенең өченче өлеше – иң катлаулысы. Ул Башкортстан башкаласы Уфада уза. Биредә конкурсантларны үз-үзеңне тәкъдир итү, портфолио, педагогик эссе, иҗади номер һәм ачык дәрес белән сыныйлар.

«Ана теле-2015» бәйгесендә Казан, Алабуга, Яр Чаллы, Бөре, Уфа, Стәрлетамак шәһәрләреннән килгән 14 конкурсант көч сынашты. Катнашучыларның бәйгегә чын күңелдән әзерләнүе, һәр өлешкә җитди якын килүе казыйларны бигрәк тә куандырды. Студентларның балаларга мәхәббәте, укытучы булу теләгенең зурлыгы 84 нче мәктәптә узган ачык дәресләр барышында да яхшы күренде.

**Гәрәева Раушания Рәүф кызы** («Ана теле-2015» педагогик осталык бәйгесен оештыручы): Моннан җиде ел элек Башкортстан республикасында «Татар теле укытучысы – 2008» бәйгесе ачылды. Бу татар теле укытучыларының республика күләмендә уздырыла торган бердәнбер көч сынашу мәйданы иде. Икенче елны, шуның нигезендә, без студентлар арасында «Ана теле - 2009» бәйгесен оештырдык. Башлангыч этабында ул факультет кысаларында гына үткәрелде һәм анда барлыгы 4 студент катнашты. 2010нчы елдан Татарстан Республикасы югары уку йортлары белән бәйләнешкә кердек, бәйгенең уздырылу территориясен киңәйттек. Быел 14 кешенең катнашырга теләк белдерүе – безнең өчен зур шатлык.



✦ «Ана теле-2015» бәйгесендә катнашучы А.Абдрахманова

**Нәсипов Илшат Сәхиятулла улы** (Татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, казыйлар рәисе): «Ана теле-2015» бәйгесе – булачак яшь укытучылар өчен зур мәйдан. Бүгеннән балаларга мәхәббәт белән янып йөргән яшьләргә юл күрсәтү гаять мөһим. Конкурсантларның креатив, сәләтле мөгалимнәр булачагы бүгеннән үк күренеп тора.

Тырышып эшләүнең нәтиҗәсе дә озак көттермәде, җиңүчеләр билгеле булды.

«Ана теле-2015» педагогик осталык бәйгесендә 1нче урынга Яр Чаллы шәһәре Иҗтимагый-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты студенты Хамматуллина Инзилә лаек дип табылды. 2нче урынны Казан Федераль университеты студенты Абдрахманова Айгөл һәм БГПУның Бөре филиалы студенты Исмәгыйлева Алсу бүлештеләр. 3нче урынга КФУ студенты Шәмсетдинов Рөстәм, БашДУның Стәрлетамак филиалы студенты Урманцева Әлфирә һәм БДПУдан Искәндәрова Флүзә лаек булдылар. Иң зур бүләк – Гран-при – КФУ студенты Нәҗипова Эльвинага бирелде.

**Эльвина Нәҗипова** (КФУ студенты): «Ана теле» кебек масштаблы чарада, бигрәк тә белем дәрәҗәсен чагылдыручы бәйгедә катнашу – үзе бер горурлык, тәҗрибә.

Бәйгенең иң төп һәм дулкынландыргыч мизгеле – 84 нче татар гимназиясендә дәрес бирү. Мин 5нче сыйныф укучыларына «Сузык һәм тартык авазлар. Сингармонизм законы» темасы буенча дәрес бирдем. Дәрестә сингапур технологиясеннән берничә алымны да кулланып эш иттем. Минем өчен иң мөһиме – дәресемнән баланың нинди дер яңалык белеп чыгуы. Аллага шөкер, укучылар бик актив җавап биреп, дәресемне күңелле вакыйгалар, үзләренең белемнәре белән баеттылар.

Бүләкләү тантанасында мине Гран-при иясе дип билгеләделәр. Татар теле һәм әдәбияты укытучысының дәрәҗәсен күтәрү һәм укучыларның тел осталыгын үстерүгә булыша торган алдынгы алымнарны ачыклауда иң яхшы нәтиҗәләргә ирешү – минем өчен зур горурлык булды!

Биредә җиңелүчеләр юк. Казыйлар һәр конкурсантның көчле ягын күрергә тырыштылар. Нәтиҗәдә иң яхшы иҗади номер, портфолио, иң яхшы интеграль дәрес, халык традицияләренә тугрылык кебек номинацияләр билгеләнде.

## • Иҗат үре

# Яңа сулыш алып, яңа көнгә!

**Светлана ГЫЙЛӘҖЕВА**

Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында эшләп килүче «Әллүки» әдәби иҗат берләшмәсендә мөһим вакыйга – әдәбият сөючеләрне куандырып, «Әллүки. Икенче китап» дип аталган тагын бер басма дөнья күрде.

Әлеге китапта Зөлфия Акмалова, Филсинә Галиуллина, Миләүшә Сәетова, Айгөл Абдрахмановаларның прозасы, Лилия Галиева, Светлана Гыйләҗева, Ильмира Камаева, Алмаз Мансуров, Зөһрә Әхәтова, Гөлназ Яппарова, Физалия Яппарова, Ләйлә Хәбибуллина, Руфинә Габдрахманова шигырьләре, Гөлназ Гатауллинаның публицистикасы, Чулпан Гобәйдуллинаның драма әсәре урын алды. Иҗатчы яшьләр арасында шигърият һәм проза өлкәләренең икесендә дә үз көчен сынап караучылар бар. Аларның да иҗат җимешләре җыентыкта урын алган. Шундыйлардан Илсөя Галиәкбәрова, Ләйсән Исмәгыйлева, Рамилә Миннехановны күрсәтеп була.

Яшьләрне борчыган темалар диапазоны шактый киң. Ул традицион мәхәббәт, яшәү һәм үлем, язмыш сынаулары һ.б. кебек гомумкешелек проблемаларны да, шулай ук милли проблемаларны чишәргә омтылуны да үз эченә ала. Әсәрләрне берләштергән бер матур як – яшь иҗатчылар аерым кешенең шәхси күңел дөньясын күзалларга омтылалар. Геройларын төрле киеренке ситуацияләргә куеп, аларны җитди сынаулар аша үткәрәләр һәм моның нәтиҗәсен гүя укучы гына түгел, ә автор үзе дә ахыргача белми кебек.

Әлеге җыентыкта урын алган әсәрләрне бәяләүчеләр алда күп булыр, әмма шунысы бәхәссез: «Әллүки» берләшмәсе шундый матур җыентыклар бастыра икән, димәк – киләчәк ышанычлы. Яңа сулыш алып, яңа көнгә бер төркем яшьләр килә.

## • Туган тел сагында

Педагогик практика вакыты – студент елларының иң матур дәверләренең берсе. Мәктәп тормышы белән кайнап алган, укытучы булып эшләп караган кызыклы да, шактый җаваплы да чор бу. Иң рәхәте, мөгаен, балалар белән әвәрә килеп, дәрес үткәрү, дәрестән тыш чарага әзерләнү мизгелләредер. Без, 10.2-002 төркем студентлары, Г.Р.Гайнуллина һәм Г.Ф.Гайнуллина җитәкчелегендә Казан шәһәренең Яңа Савин районы «Татар телендә белем бирә торган 155 нче номерлы гимназия» гомуми белем бирү муниципаль бюджет учреждениесендә педагогик практика үтәбез.

# Мәктәптә әдәби мохитне җанландырабыз

**Руфинә ГАБДРАХМАНОВА**



Халыкара туган тел көне һәм Әдәбият елы уңаеннан, 27 нче февраль көнне мәктәп күләмендә Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланган «Без хәтерлибез!» дип аталган әдәби-музыкаль чара үткәрдек. Бу чарага әзерләнү барышында укучылар белән вальс өйрәнүләр, шигырь ятлаулар, номерлар арасындагы күренешләрне кабатлаулар дисеңме – гаҗәеп кызык һәм онытылмас мизгелләр! Сугыш вакыйгаларын сәхнәләштерүдә 8, 10 нчы сыйныф укучылары аерылып торды. Концерт номерларына килгәндә, 7 нче сыйныф укучылары Муса Җәлил, Р.Фәйзуллин шигырьләрен, М.Мәһдиевнең сугыш турындагы әсәрләреннән өзекләрне сәнгатьле сөйләү буенча үз сәләтләрен күрсәтте. 12-13 яшьлек балаларның шулкадәр аңлап, хискә бирелеп сөйләгәннәрен күптән ишеткән юк иде. Бик матур булды чыгышлар, зал тын алмыйча тыңлады.

Мәктәп тормышында без татар әдәбияты мохитен җанландырып җибәрдек кебек. Бүгенге көндә фронтовик шагыйрь Сибгат Хәкимнең тормыш һәм иҗат юлына багышланган мәктәпкүләм чара хәзерлибез.

**• Бөек җиңүгә - 70 ел!**

«Яшь кеше!
Син минем яшемә җиткәндә, мин инде җирдә булмам. Бу котылгысыз аерылу алдыннан мин сиңа кечкенә генә хат язып калдырам.
Син әле мәктәптә укыган көннәрдә үк җиреңнең тарихы белән, халыкларның тормыш юллары белән танышырсың. Синең күз алдыңнан бик ерakta калган гасырлар узып китәр. Нинди генә исемнәрне күрмәссең син ул тарих битләрендә! Нинди генә хәлләрне очратмассың син ул чорларда! Ниһаять, син шулай, тарих битләрен берәмләп ача-ача, безнең гасырга, без яшәгән чорга килеп җитәрсең. Һәм син анда «фашист» дигән сүзне күрерсең. Кем иде соң ул фашист? Мин сиңа шул турыда сөйләргә телим.
Фашизмны онытырга ярамый!» (Нәби Дәүли).

# Әбием күңелендәге яра

**Руфия ХӘСӘНОВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

**Кызыклы факт:**
**1941нче елның 23нче июнендә Хәрби көчләр белән идарә итүнең югары органы булдырыла.**

Әбиемә – Хәсәнова Маһисәрвәр Мәсгут кызына – шушы юлларны укып күрсәткәч, ул, авыр сулап, күңелдәге яра җөйләрен барлый башлады. Кешегә ни җитмидер?! Шайтан котырта, күрәсең. Чит җирләр, чит байлыклар күзне кызыктыра, күңелне кузгата. Ләкин бер генә халыкның да үз туган илен, үз газиз җирен башкалар белән бүлешәсе килми. Нәтиҗәдә һәр сугыш, ике якка да – башлаучыларга да һәм үз илен яклаучыларга да – зур югалтулар, исәпсез-хисапсыз корбаннар, күз яшьләре, ятимнәр, үкенүләр, сугышны оештыручыларны каһәрләү генә китерә. Халык боларның барысын да аңлый, ләкин канлы сугыш уты, кемнәрнеңдер нәфес хисе аркасында, әле бер илдә, әле икенче дәүләттә кабынып тора...

1941 нче елның 22 нче июнендә фашистлар Германиясенең җинаятьчел һөҗүме белән башланган Бөек Ватан сугышы елларында илебез халкы искиткеч авыр сынаулар узды. Кайгы уртак, хәсрәт бер иде, моны аңлаган һәр намуслы гражданин Ватан каршында үз бурычын үтәргә антлар эчте, сабыр булырга туры киләчәген аңлады.

1941 нче ел. Сызылып кына таң ата, нигәдер кояш бүген бик иренеп, кан сыман кызыл төстә



булып тау башына күтәрелде. Сабыйлар, берни сизмичә, татлы төшләр дөньясында йөзеп, әти-әниләр, әби-бабайлар изрәп йоклыйлар. Кинәт, барлык хыялларны чәлпәрәмә китереп, аяз күктә яшен яшьнәгәндәй, нидер шартлаган тавыш ишетелде. Әбиләр «Бисмилла» укый башлады, балаларның ачыныл елаулары, әниләрнең сабыйларын юату тавышы бөтен дөньяга таралды. Шундый тыныч иртәдә безнең Ватаныбызга фашист козгынының беренче һөҗүме иде бу. Сугыш башланды.

Минем әбием сугыш турындагы язмаларны, кинофильмнарны күз яшьләрсез карый алмый. Бу хакта сорасаң, йөрәген тота башлый. Тик шулай да бер язгы җылы иртәдә мин, бөтен көчемне җыеп, әбиемнең күңел кылларын тетрәндергән сугыш вакыты турында истә калганнарын сөйләтергә булдым.

**– Әбием, сугыш башланганда сиңа ничә яшь иде?**

– И кызым, – диде әбием һәм һавага карап уйга калды. – Ул көннәрне кичә булган кебек хәтерлим, төннәрен төштә күреп уянам. Миңа 5 яшь иде.

**– Ә явыз фашистлар илебезгә аяк басканын каян ишеттең?**

– Радиода дикторның матур тавышы, кинәт авыр төер йоткандай, калын тавышка әйләнде һәм Ватаныбызга чит явызлар аяк басканлыгын әйтте. Әниемнең, мине күкрәгенә кысып, күз яшьләрен яшереп үксегәнен әле дә хәтерлим.

**– Сиңа бик авырга туры килгәндер инде? Ул еллардагы бер көнеңне тасвирла әле.**

–Кызым, хәзерге заман кешесенә мин күргәннәрне аңлатуы бик кыен ул. Тасвирларга сүзләр дә җитмәс. Донбасс шәһәрендә яши идек бит. Таң белән бергә торасың, басуга эшкә барып, төн җиткәнче, күзләр күрмәс булганчы эшлисең, бар хезмәт фронтка китеп барды (елый). Барлык авыр эш хатын-кызлар, карт-коры, балалар җилкәсенә төште. Ашау юк, алабуталар җыеп ашата иде әни. Үзенең авызыннан өзеп үстерде инде ул безне.

Әбиемне тынычландыру өчен, өстәл янына чәй эчәргә чакырдым. Бераз утыргач, ул башын аска иеп:

– Төннәрен дә йокламый иде әни, фронтка киткән әтиебезгә булсын дип, оекбаш-бияләйләр бәйли иде, – дип дәвам итте. – Сугыштан кайткач, әтием сугыш кырында әнигезне күз алдына китереп кенә исән калдым, дия иде.

**– Менә бит, шундый вакытта да бер-берсен ярату сакланган.**

– Кызым, мин немецның үзен күрдем бит. Әниләр басуга киткән вакыт иде, мин өйдә ялгызым. Берзаман солдат киеме кигән өч ир-ат өебез ишеген каерып ачты. Берсе миңа мылтыгын терәп:

– Курка, яйка, малака, – диде. Бу аларның миннән тавык, йомырка, сөт сораулары булган икән. Күземнән яшьләр акты, шунда бу өч ир-атның берсе, мылтык терәгәненә нидер аңлатты да мине түбән өйгә төшереп бәйләп куйдылар. Фашистларның да олы йөрәклеләре була икән ул. Шулай алар мине исән калдырды.

Әбием яулык чите белән күз яшьләрен сөртте дә башка бүлмәгә чыгып китте. Мин үз уйларым белән калдым. Без, яшьләр, бәхетле буын, чөнки безгә сугыш дигән явызлыкны күрергә туры килмәде һәм килмәсен дә. Шуның белән без бәхетле дә инде!

**• Хәтер-хатирә**

Безнең уку йортындагы кебек мөмкинлекләр тагын кайда бар икән? Уку, ял итү, күңел ачу турында әйтеп тә торырга кирәкми! Укудан арып-талып, туган нигезендәй якын тулай торакка кайту – нинди зур бәхет бит! Ә авылдан килеп укучыларга, гомумән, бик рәхәт. Алар авылдан «авылга» килә.



**Илмир ВӘЛИЕВ,** Математика һәм механика институты

# Үзеңнеке үзәктә

Академик Парин урамында урнашкан «авыл» бер дә гади түгел. 2013 елда Казаныбызда узган XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиада ярышлары чорында бирегә 170тән артык илдән килгән 13500 спортчы һәм тренер яшәде.

Бөтен гомерен студентларның яшәү шартларын яхшыртуга багышлаган, бүгенге көндә Универсиада авылы мэры киңәшчесе булып эшләүче хөрмәтле Илгиз ага Абдуллин белән аның күңелендәге хатирәләрне яңарттык.

«Билгеле булганча, Идел буенда урнашкан Казан шәһәре – илебез тарихында һәрвакыт күренекле һәм мактаулы урын алып торучы шәһәрләрнең берсе. Казанда 210 ел элек хәзерге Казан (Идел буе) федераль университеты, 1876нчы елда Укытучылар институты ачыла. Аннан соң Укытучылар институты – Казан дәүләт педагогика институтына, ә соңыннан Татар дәүләт гуманитар педагогика университетына үзгәртелә. Мин 1974нче елдан КДПУда административ-хуҗалык эшләре буенча проректор вазифаларын башкардым.

Гомумән алганда, дәүләт вузларының материаль-техник базасын үстерү юнәлешендә һәрвакыт зур эш алып барылды. Тулай торак мәсьәләсенә килгәндә, Бөек Ватан сугышы вакытында КДПУ шәһәрчеген Суворов училищесына бирәләр. Шул вакыттан соң, университет яңадан «туа» башлый. 70нче елларда ректор М.Зәкиев җитәкчелегендә университетта зур эшләр эшләнде, яңа биналар төзелде, искеләре торгызылды. Хөкүмәт карары нигезендә, Пушкин урамында, соңрак Академик Парин, Х.Мәүлетов урамнары кварталларында студентлар шәһәрчеге төзелергә тиеш иде. Бу планнар барып чыкмады. Ләкин соңгы планда каралган урын университетныкы булып калды. Әлеге территориядә Универсиада авылы төзелде. Бу комплекс төзелгәнче үк, Универсиада тәмамланганнан соң, андагы өйләрдә КФУ студентлары торачагы турындагы килешүгә кул куелды. Планнар барып чыкты: Универсиада авылы – КФУ студентларыныкы.

Хәзерге көн белән чагыштырып, 70-90нчы еллардагы студентлар тулай торaklары мохитенә тукталасым килә. Ул заманнарда да безнең тулай торакларда яшәү шартлары башка уку йортларыныкыннан ким түгел иде. Студентлар һәр нәрсәнең кадерен белеп яшәде, университетның материаль-техник базасын яхшырту буенча студентлар тарафыннан актив эш алып барылды. Тулай торакларны төзегән вакытта, университетның һәр студенты, бу зур эшкә үз өлешен кертте: кемдер төзелеш бригадаларында штукатур-маляр, төрле эшләрдә ярдәмче булып эшләде. Һәр студентка акчалата түләү каралган иде. 50-60 көн эчендә студент 800 сумга якын акча эшли ала иде. Ул вакыт өчен бу – бик зур акча. Төзелештә катнашучылар өчен индивидуаль уку планы төзелде. Шулай итеп, студентларга өстәмә һөнәр үзләштерү мөмкинлеге булдырылды. Үзең эшләгәнең кадере дә зуррак бит. Шуңа күрә тулай торакларда яшәү кагыйдәләрен бозу, әйберләрне җимерү күренеше бер дә күзәтелмәде, киресенчә, җыештыру, төрле төзәтү эшләрен студентлар үзләре башкарды. Хәзерге студентлар да һәр әйбернең кадерен белсен иде. Моның өчен мораль-этик, эстетик тәрбия бирү юнәлешендә күп эшләргә, студентларның активлыгын арттырырга кирәк. Мин эшләгән чорда, университет студентлары яңа ачылган лаборатор үзәкләр өчен кирәк булган җиһазларны, карталарны да үзләре ясады.

Ашау-эчү мәсьәләсенә килгәндә, студентлар Л.Толстой урамында урнашкан вузара гомуми ашханәдә ашый иде. Хәзер бирегә – КХТИ бинасы. Ашханәнең чыгымнарын хөкүмәт үзенә алу сәбәпле, ашау-эчү ягы шактый арзан булды. Гомумән, хөкүмәт уку йортларына ул чорда да матди яктан бик зур ярдәм күрсәтте.

1960нчы елларда «Яльчик» лагерена да нигез салынды. Әлеге савыктыру лагере да студентлар кулы белән эшләнде. Хәтта төзү материалларын да студентлар үзләре Киров өлкәсеннән – төзелеш бригадаларында эшләгәннән соң алып кайта иде. Авыр вакытларда да «Яльчик» лагере студентлар көче белән эшләвен дәвам итеп, хәзер дә студентларның ял итү урыны булып тора.

Менә шулай элекке студентлар көче белән тупланган бай мирасны бүгенге студентлар аеруча кадерләп, саклап торсыннар иде. Үткән белән киләчәкне тоташтыручы бүгенгебез белән горурланып яшик!»

• Безнең канат

# Инициатива таләп итүче проект

**Илмир ВӘЛИЕВ,** Математика һәм механика институты

Март аенда мәркәзебездә яшь лидерларны сайлап алу, аларны өйрәтү, илебез өчен мөһим булган социаль эшчәнлеккә кызыксыну уяту системасын булдыручы «Кадрлар резервы» проектының беренче этабы башланды.

Әлеге этапның темасы Бөек җиңүнең 70 еллыгына багышланган. Шуңа күрә һәр катнашучының максаты – темага туры килгән, башкаларныкыннан аерылып торган, эчтәлекле, нәтиҗәле чара уздыру. Проектта катнашырга университетыбыз студентлары да теләк белдергән. Мәсәлән, Икътисад, идарә һәм финанслар институты студенты Илфат Вәлиев, биремне югары дәрәҗәдә башкарып, менә дигән чара уздырган.

**– Илфат, үз эченә актив яшьләрне җыйган «Кадрлар резервы» проекты – бүгенге көндә иң популяр, әйдәп баручы проектларның берсе. Белгәнемчә, үзеңне проектта дип санау өчен, сайлап алу этабын узу мөһим. Ә син проектка ничек килеп кердең?**

– Чыннан да, университетыбыз, республикабыз, илебез өчен янып йөргән һәр студент та проект белән якыннан таныш. Бу проект республикабызда беренче ел гына үткәрелми. 2009нчы елда старт алган проектның сайлап алу турында меңнән артык кеше катнашты. Катнашучылар арасында – студентлар, республикабызның төрле районнарыннан килгән яшьләр. Әңгәмә формасында узган сайлап алу туры 4 көн дәвам итте. Әлеге этапны уңышлы узган 150 кешене «Идел» ял итү базасына җыйдылар. Биредә проектлар ясауга, аларны тормышка ашыруга, финанс якларын



жайлауга һәм башка кызык сорауларга багышланган дискуссияләр, уеннар үткәрелде. Хәзер исә, өйрәнгәннәрне файдаланып, үз проектыбызны булдыру өстендә эшлибез.



**– Үз чараңны уздыру, үз проектыңны яклау җиңел башкарыла торган эшләрдән түгел бит. Ә син нинди дә булса авырлыкларга юлыктыңмы?**

– Башкарыла торган һәрбер эшнең үз үзенчәлеге бар, әлбәттә. Проект кысаларында үз чараңның дөрестән дә кызыклы, кирәкле икәнлеген исбатлау процессы минем өчен бик тә кыен булды. Ник дигәндә, проектта барлык чаралар да ел буена билгеләнгән план буенча уздырыла. Хәтта «Сез безнең планга үз чарагыз белән «төзәтмәләр» кертергә телисез», – дигән сүзләр дә ишетергә туры килде. Бу очракта инициативалы булу кирәк, минемчә.

**– Шундый зур чараны әзерләүне үзең генә башкарып чыктыңмы?**

– Юк, әлбәттә. Мөмкинлектән файдаланып, бу чараны уздырырга булышкан өчен, Казан шәһәренең Авиатөзелеш районының Мәктәптән тыш эшләр үзәге мөхәррире Бугрова Валерия Вячеславовнага рәхмәтемне җиткерәсем килә. Бары тик аның җитәкчелегендәге командa ярдәме белән генә чара уңышлы узды. Гомумән алганда, нинди дә булса проектны гамәлгә ашырганда, дусларның, якын кешеләрнең ярдәме бик мөһим, чөнки ялгызыңа бу эшне башкарып чыгу бик авыр. Ә калган авырлыкларга килгәндә, алар бары тик оештыру моментларына гына бәйле. Гомумән алганда, кечкенә генә кимчелекләр булуына карамастан, барысы да яхшы узды.

• Син+Мин=БЕЗ!

Югары уку йортына укырга керү – тормыш китабының яңа сәхифәсе. Сине яңа мохит, яңа кешеләр уратып ала. Шул яңалык арасында син үзеңне таба алырсыңмы? Ә мин таптым.



# Безгә сокланмый мөмкин түгел

**Динә СӘЙФЕТДИНОВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Укытучылык дөньяда иң изге, мәрхәмәтле, кешелекле һөнәр икәнен аңлау мине Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтына китерде. Төркемдә без 37 кыз һәм бер егет. Татар филологиясендә мондый зур группа бик еш булмыйдыр. Университет тормышына беренче адымнар ясаганда, барысының да хәтта исемнәрен белеп бетерә алмам кебек тоелды мина. Ләкин борчуларым юкка булган, атна-ун көн дигәндә, без инде барыбыз да дуслашып, туганлашып беттек, дияргә була.

Нәкъ тә менә авыр вакытларда кемнең кем икәне ачыклана, чын дуслар сынала. Минем төркем дә имтиханнарда чын сынау үтте. Мине иң гаҗәпләндергәне – шулай тиз берләшеп, бер-беребез өчен җан атып торуыбыз.

Безнең төркемнең унган кызлары һәм бердәнбер егет орчык сыман тиктормаслар, дисәң дә, ялган булмас. Төрле бәйгедә сыналып, беренчелекне яулаумы, җанатар булып барумы, очрашуларда катнашумы, берләшеп ял итүме... Бер төркем булып җыелсак, сокланмый мөмкин түгел. Бердәмлегебез, дуслыгыбыз һәрвакыт күренә.

Киләчәктә дә үзебезнең куйган максатларыбызга ирешербез, дип ышанасы килә, чөнки бердәмлек һәм теләк булганда, төрле киртәләрне узу җиңел. Ә безнең максатлар тормышчан, чынга ашардай. Җәмгыятькә файдалы шәхес, чын укытучы, әтиәниемнең, илемнең горурлыгы булу бер минем генә хыялым түгел, ул – барлык 10.2-404 нче төркем студентларының тормыш максаты икән! Бәлки, нәкъ менә шул безне берләштерәдер дә!

• Сәяхәттән кайткач

# «Эшлә һәм сәяхәт ит!»

Җәй исе килә башладымы, сессияләрен япкан студентлар аны ничек үткәрү турында уйлана. Кемдер ял итә я эшкә урнаша. Сәяхәт һәм акча эшләүне дә берләштереп була бит. Мәсәлән, Экология һәм табигый байлыклардан файдалану институты студенты Айрат Мотыйгуллин АКШта булып кайтты.



«Америкада булганда, минем күңелдә өч төрле хис өстенлек итте: азатлык, җаваплылык һәм туган якны сагыну»

*Сәяхәтнең башы*

«Work&Travel» программасы буенча Америкага сәяхәт АКШ илчелеге тарафыннан рөхсәт ителгән виза алудан башланды. Виза алу мәсьәләсе – үзе дулкынландыргыч мизгел: Мәскәүгә барулар, илчелектә, каушый-каушый, әңгәмә үтүләр, дисеңме…

Китүгә бер атна кала, мин барысын да энәсенә, җебенә кадәр тикшереп, планлаштырып куйдым. Болай эшләү вакыт һәм финанс ягын шактый җиңеләйтә.

Самолетка утырдым, җирдән күтәрелдем. Шул вакыт күңелемне кызыклы хис биләп алды: үз-үзеңә ышанмыйча, артка юл юк икәнен аңлыйсың, ә алда ни буласын кем белгән?!

Нью-Йоркның Кеннеди аэропортына аяк басу белән икенче сулыш ачылгандай була. «Туган йортымнан меңләгән чакрымнар ераклыкта бит мин. Гомумән, башка континентта!» дип уйлап, кайчандыр хыялда гына йөрткән яки телевизор экраннары аша күргән күперләр, күккә ашкан биек биналар, данлыклы мәйданнар – барысы да синең ихтыярыңда икәнен күрәсең. Шуны аңлыйсың да, үзеңне шулкадәр бәхетле һәм иркле итеп тоясың. Миңа калса, һәр сәяхәтчедә шундый хисләр уянадыр.

*Кешеләрнең була төрлесе*

Нью-Йорк шәһәре кешеләренең гадилегенә таң калырлык: ярдәмгә атлыгып торалар, елмаюларын бер дә кызганмыйлар. Беренче көннәрдә шәһәр метросын аңлый алмыйм интектем. Билгеле бер җиргә барып җитәр өчен, кайсы җирдән, нинди электропоездга утырырга белми аптырап йөргәндә, әлбәттә, кешеләргә мөрәҗәгать иттем. «Бу станциягә ничек барып җитәсе?», «Кирәкле юнәлештә китәр өчен, кайда басарга кирәк?» кебек сорауларыма җавап бирүдән тыш, кайберләре, хәтта үз поездларыннан төшеп калып, озатып та йөрделәр. Һәрвакыт нииндидер кызыклы вакыйга сөйләп, киңәш биреп, бу кешеләр Америка кебек дәүләтнең чын яшәешенә кереп китәргә ярдәм иттеләр.

*Мейн, каршы ал безне!*

Нью-Йоркның серләрен өч көн дәвамында белергә тырыштык, тик инде Мейн штатына китәргә вакыт җиткәнен аңладык. Бу – АКШның төньяк-көнчыгышындагы штат. Биредә без 3 ай буе эшләргә тиеш. Ресторан менеджерлары бик кунакчыл каршы алды, яшәү урыннары эзләүдә ярдәм иттеләр. Бу эштә безнең белән бергә, Филиппин утравы, Ямайка, Сербия, Болгария, Казакъстан студентлары да эшләде. Яңа күнекмә, сәләтләргә дә баедык: төрле сендвич, пицца, кайнар ашлар, салатлар ясарга өйрәндек. Мин үземә өстәмә эш тә таптым – кунакханәгә эшкә урнаштым. Шулай итеп, иртәнге 9.00дан төнге 01.00гә кадәр эшләп, атнага бер көн генә ял итеп, Америка буенча булачак сәяхәтемнең финанс ягын кайгырттым.

*Таныш булмаган Америка*

Сентябрь башында сәяхәткә кузгалдым. Чит континентның табигатен дә күзәтү өчен, штат белән штат арасын иң арзан транспорт – автобус белән гиздем. Автобуста сәяхәт итү һәр юлчыны ниндидер аңлатып булмаслык тәэсирләр белән баета. Нью-Йорк, Бостон, Портленд, Чикаго, Вашингтон, Атланта, Орландо, Майями, Яңа Орлеан, Хьюстон, Сан-Антонио, Даллас, Лос-Анджелес, Лас-Вегас һәм Сан-Франциско кебек эре шәһәрләрдә булган көннәремне, анда танышкан яңа кешеләрне һәр көн диярлек хәтеремдә яңартам.

Әлеге дәүләттә дөньяны башкача кабул итәсең. Үзеңне үзенчәлекле тоясың, чөнки син турист кына. Америкада булганда, минем күңелдә өч төрле хис өстенлек итте: азатлык, җаваплылык һәм туган якны сагыну. Бу сәяхәттән соң бөтен кешеләргә дә күбрәк сәяхәтләргә чыгу кирәк дигән нәтиҗәгә килдем, чөнки чит җирләрдә булу дөньяга карашны киңәйтә, тормышны онытылмас, якты хисләр белән баета.

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: Э.Р.Һадиева
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Профсоюзная, 17в.